ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Колхозная, дом 1,
село Шланга, 422474
ИНН 1617003275

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Колхоз урамы, 1нче йорт,
Шланга авылы, 422474

Тел.: (84375) 3-91-36, 8(9377754063), факс: (84375) 3-91-36, e-mail:
Shlang.Drz@tatar.ru,

---

2022 нчы елның 28 январе № 1

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Шланга авыл җирлегендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә
күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм “2022 елда пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 27.01.2002 карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлегендә № 1 нче кушымта һәм № 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 6964 сум 68 тиен итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Шланга авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 ел 29 январь 5 нче номерлы “Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында” карарын 2022 елның 1 нче февраленнән гамәлдән чыккан дип санарга.
3. Әлеге карарны авыл җирлеге мәгълүмати стендында халыкка игълан итәргә һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Шланга
авыл җирлеге башлыгы: И.И.Якупов

Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлеге Башкарма
комитетының
2022 елның 28 январь 1 номерлы
карарына
1 нче кушымта

Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Күмү өчен табут һәм башка кирәк яраклар бирү һәм китерү | 3748,3 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) ташу | 1023.11 |
| 4. Кабер казу һәм җирләү | 2193.18 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлеге Башкарма комитетының
2022 елның 28 январь 1 номерлы карарына
2 нче кушымта

Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге

| Наименование услуг | Стоимость услуг (в руб.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тәнне киендерү | 395,94 |
| 3. Күмү өчен табут һәм башка кирәк яраклар бирү һәм китерү | 3352,45 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) ташу | 1023,11 |
| 5. Кабер казу һәм җирләү | 2193,18 |
| Барлыгы | 6964,68 |